Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Советының бишенче чакырылышының җиденче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы карары

26 март, 2026 ел № 48

Питрәч ав.

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2023 елның 7 декабрендәге 288 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2023 елның 7 декабрендәге 288 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру нәтиҗәләре турында мәгълүмат» 5 бүлегенең 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планнарына (программаларына) кертелгән унитар предприятиеләрнең, акционер җәмгыятьләрнең һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрнең әлеге пунктта каралган аралык бухгалтерлык (финанс) хисабы бухгалтерлык (финанс) хисабының дәүләт мәгълүмат ресурсын булдыру максатларында тапшырылырга тиеш түгел.».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов